**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№2134**
**07.05.2020**

Башкарма комитетның 2014 елның 20 февралендәге 1026 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Сатулар үткәрү турында мәгълүмат урнаштыру өчен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясенең рәсми сайтын билгеләү һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2012 елның 10 сентябрендәге 909 номерлы карарының 1 пункты, Россия Федерациясе Граждан кодексының 448 статьясы, «Реклама турында» 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясы, Шәһәр Советының 2013 елның 30 маендагы 25/8 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү тәртибе турында нигезләмәнең 43 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2014 елның 20 февралендәге 1026 номерлы карары (2017 елның 27 гыйнварындагы 353 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре территориясендә реклама конструкцияләрен урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә килешүләр төзү хокукына аукционнар әзерләү һәм үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 11 пунктта:

- 1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) аукцион үткәрү турындагы хәбәрне, аукцион үткәрүдән баш тарту турындагы хәбәрне «Челнинские известия» газетасында (алга таба - рәсми басма) бастырып чыгара һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында һәм Россия Федерациясенең рәсми сайтында www.torgi.gov.ru (алга таба - рәсми сайтлар) урнаштыра;»;

- 2 пунктчада «рәсми сайтка» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

2) 19 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19. Аукцион үткәрү турындагы хәбәр аукцион үткәрү көненә кадәр кимендә 30 көн алдан, аукцион документларын рәсми сайтларда урнаштырып, рәсми басмада бастырып чыгарыла.»;

3) 29 пунктның өченче абзацында «рәсми сайтка» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

4) 30 пунктта «рәсми сайтка» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

5) 31 пунктның 7 пунктчасында «рәсми сайтка» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга;

6) 47 пунктта «рәсми сайтка» сүзләрен «рәсми сайтларда» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.З. Исхаковка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов